Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № LI-7**

Балык Бистәсе штп.

2024 елның 22 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Анатыш, Балыклы Чүкәй, Бәтке, Биектау, Олы Елга, Олы Кульга, Зур Мәшләк, Олы Әшнәк, Олы Солтан, Казак Чаллысы, Корноухово, Күгәрчен, Күки, Котлы Бөкәш, Масловка, Түбән Тегермәнлек, Яңа Арыш, Полянка, Рус Әшнәге, Троицкий Урай, Уракчы, Шомарбаш, Югары Ырга, Шумбут, Шумково, Балтач авыл җирлекләре вәкаләтләрен кабул итәргә:

- мәет җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү;
- мәет җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибен билгеләү;
- җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге сыйфатына карата таләпләрне раслау;
- җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау;
- ире, якын туганнары, башка туганнары яисә вафат булган кешенең законлы вәкиле булмаганда яисә алар тарафыннан җирләү мөмкин булмаганда вафат булганнарны (һәлак булганнарны) җирләүгә хезмәт күрсәтү бәясен раслау, шулай ук өйдә, урамда яисә шәхесенең эчке эшләр органнары билгеләгәннән соң башка урында үлгән кешене җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлар булмаганда;
- шәхесе Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнмәгән үлгәннәрне (һәлак булганнарны) күмүгә хезмәт күрсәтү бәясен раслау.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына:

- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре Башкарма комитетлары белән килешүләр төзергә;

- карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында бюджет законнары нигезендә 2025 елга, 2026 – 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы карары проектында финанслауны күздә totarга.

3. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирлекләре бюджетларыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына бирелә торган финанс чаралары исәбеннән тормышка ашырыла.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов